ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
**11.04.2019**

Зеленодольск
шәһәре

**КАРАР**
**№ 880**

Зеленодольск шәһәренең Энгельс урамындагы 14 нче, 20 нче күпфатирлы йортларга капиталь ремонтлау эшләрен башлау турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 елның 17 мартындагы 550-р номерлы күрсәтмәсе нигезендә, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. «Зеленодольскгаз» эксплуатация – житештерү берләшмәсенә, «ЗВКС» АЖ, Идел буе бүлекчәсе Зеленодольск ОКО -«Татэнергосбыт» ААЖ түбәндәге адреслар буенча торак йортларны коммуникацияләрдән өзәргә тәкъдим итәргә:
- Зеленодольск шәһәре, Энгельс ур., 14 нче йорт;
- Зеленодольск шәһәре, Энгельс ур., 20 нче йорт.
2. 2019 елның 16 апреленнән «Жилкомплекс» ҖЧҖ идарәче компаниясенә күпфатирлы йортлар белән идарә итүне һәм күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәтне карап тоту һәм ремонтлау өчен түләүләрне исәпләүне туктатып торуны гамәлгә ашырырга.
3. 2019 елның 16 апреленнән «Татинвестстрой» ҖЧҖ подрядчыларына күпфатирлы йортларны капиталь ремонтлау эшләренә керешергә. Дәүләт контракты шартлары нигезендә күпфатирлы йортларга капиталь ремонтлау эшләрен төгәлләү срогын 2019 елның 31 декабренә кадәр билгеләргә .
4. ЗМР Советы аппаратының җәмәгатьчелек, массакүләм мәгълүмат чаралары белән элемтә бүлеге начальнигы Д.С. Анисимовка әлеге карарны массакүләм мәгълүмат чараларында Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы сайтында яисә «Зеленодольская правда» газетасында урнаштыру юлы белән бастырып чыгаруны тәэмин итәргә.
5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче Д.А. Сапожников